ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2023 г. Казань № 493-17/т-2023

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж ташуга 2024 елга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

«Автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутларда автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуга җайга салына торган тарифлар билгеләү тәртибе, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2023 елның 12 декабрендәге 53-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча

муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь дәрәҗәдә чик тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2023 № 493-17/т-2023
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| т/с | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗә максималь тариф (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Автобус белән пассажирлар йөртү | сум/пасс./ км | 2,40 |
| 2. | Автобуста бер урын багаж алып бару | сум/км | 0,36 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге